| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ОЛЫ ЕЛОВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ Олы Елово авылы КАРАР

№ 145 «25» ноябрь 2024 ел.

Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге Советының 28.04.2018 елгы 109 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында " Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында «28.03.2018 ел, № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.09.2024 ел, № 829 карары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр, муниципаль хезмәткәрләр", Олы Елово авыл җирлеге советы

**Карар кабул итте:**

1. Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, № 109 карары белән расланган «Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладлар, биләгән муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына тапкырланган күләмнәрдә 13 990 сум күләмендә билгеләнә».

1.2. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Нигезләмәгә 1 нче кушымта

"Башлыкны айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

муниципаль берәмлектә, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затлары, Алабуга муниципаль районының Олы Елово авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре, сумнар |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 19 173 |

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш һәм 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис урынбасары Т.Р.Музлова